

**ЭЛЬС ГАДЕЛЕВ**

**(1936 – 2002)**

Татарский поэт, переводчик, журналист, диктор республиканского радио, обладавший голосом редкой красоты и тембра.

Эльс Гаделев уроженец деревни Салауши Агрызского района.

Эльс Гаделев – один из тех творцов, для которого процесс работы всегда был важнее её результата. Он писал стихи, а уж публикация для него являлось делом вторичным. Вернее, публикации у него были – газетные, журнальные… – а вот конечного продукта, своей книги, – нет, не было. Её выпустили в свет после смерти поэта его собратья по перу и коллеги – Разиль Валеев, Марсель Галеев, Рустем Набиуллин... Иные говорят про него, что он был просто несобранным человеком, потому и не удостоил себя своим поэтическим сборником, слишком разбрасывался – временем, способностями, профессиями... Если сравнивать с русскими поэтами Казани, он был породы Леонида Топчия, Юрия Макарова, Геннадия Капранова… Действительно, целеустремлённым назвать Эльса Гаделева было трудно. В этом есть доля правды. Однако и яркое разнообразие его талантов не оспоришь. Он владел, например, редкой красоты и тембра голосом чтеца. Наверное, все знают голос Юрия Левитана – ну вот, э т о примерно то же самое. Только на татарском языке. Эльс Гаделев долгое время работал диктором на республиканском радио. И его передачи – будь то сводки с сельскохозяйственных полей или расписание поездов –слушали как какое-то завораживающее слух художественное произведение, как какую-то волшебную оперу... Он был поразительно эрудирован, хорошо знал татарскую и всемирную литературу. Эльс отличался весёлым нравом, остроумием и профессиональной чуткостью к художественному слову. Легко и даже как-то играючи переводил стихи и прозу. Сам же и публикации обустраивал. А вот о себе позаботиться не мог. По большому счёту почивать на лаврах ему не довелось – ни в одной профессии, ни в поэтическом творчестве, ни в быту – нигде. Оставил после себя разрозненные рукописи, заметки, дневники... И вот, наконец, с помощью настоящих друзей поэтическое наследие его увидело свет. Только обидно, когда автор не видит свою новорождённую книгу!

Аны тыңлаганда, татар булып тууыңа шөкерана кыласың. Бу тавыш – туган телебезнең яңгырашына мәхәббәт уяткан тавыш!

Аның иген-ипкә китереп әйткән һәр сүзенең мөкәммәл олылыгын танып сөйләү рәвеше – үзе бер сәнгать иде. Эльс Гаделев татар радиосында, диктор буларак, үз чорының мәгънәле сәхифәсен тудырган.

Әйе, бүгенге дикторлар (ир-атлар) күбесе Эльс Гаделев тавышы белән сөйләргә тырыша. Әмма... тавыш матурлыгы гына йокымсыраган эчке аң ваемсызлыгын яшерә алмый шул. Эльс Гаделевнең сөйләү рәвеше башка иде... Аның фикер иясе икәнлеге, зыялы рухы, үз милләтенә булган мәхәббәте, саллы иңенә халык тарихын күтәрә алу кодрәте бәгырьдән күтәрелгән тавыш тембрында сизелеп тора иде.

**Эльс Гыйният улы Гаделев** 1936 елның 16 декабрендә Яшел Үзән районы Олы Шырдан авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Ул елларда шундый тәртип була: кайсы төбәк мәктәбенә укытучылар җитми, мәҗбүри рәвештә диярлек, мөгаллимнәрне яшәгән нигезеннән кубарып, шунда җибәрә торалар. Гыйният ага да, җәмәгате Гөлҗиһан белән балаларын ияртеп, Әгерҗе төбәгенә килеп төпләнә.

Шулай итеп бәрәкәтле Салагыш туфрагында үскән Эльс атлы егет, җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Минзәлә педучилищесына укырга керә. 1955 елдан – Казан дәүләт педагогия институты студенты. Югары уку йортын тәмамлаганчы ук, ул Татарстан радиокомитетында диктор булып эшли башлый һәм гаҗәеп тавышы белән Казанны гына түгел, ә бөтен татар галәмен яулап ала. Эльс Гаделевнең бәрхет тавышы, ил киңлекләренә таралып, хәерле иртә теләп уята, көннең имин буласына ышаныч тергезә, кичләрен исә, тормыш-гамәлләребезгә йомгак ясап, көнне түгәрәкли иде. Әнә шулай бай, хикмәтле тавышы белән ул җәмгыять фикерен, дәүләт фикерен, әдәбият, сәнгать яңалыкларын халыкка радио аша җиткерә барып, дикторлыкның нәкъ менә татарга хас кимәлендә, үз мәктәбен булдырды.

СССРның мәшһүр дикторы, бигрәк тә сугыш елларында үзенең гаярь кодрәтле тавышы белән күпме халыкка ихтыяр көче биргән Юрий Левитан да, Казанга килгәч, Эльс Гаделевне тыңлап, аның сөйләм сәләтенә югары бәя биргән.

Егәрле сөйли белү һәм сәнгатьле яза белү... Бу ике сәләт тә Эльс Гаделевкә бердәй югарылыкта бирелгән иде. Төрле редакцияләрдә эшләгәндә, аның газеталарда кызыклы язмалары дөнья күрде. Ул тәрҗемә эше белән дә шөгыльләнде. Русчадан татарчага яисә татарчадан русчага бердәй җиңеллектә тәрҗемә итә, күп вакыт язып та тормыйча, текстка карап, машинисткага әйтеп кенә тора иде. Эльс Гаделевнең шигърияте – үзе бер ачылмаган дөнья. Үзе өчен генә дип гомере буе шигырь язды ул. Инде бик сорап, аптыраткан чакларда гына аз-маз шигырьләрен матбугатка биргәләде. Әмма, тулаем бер җыентык туплап, китап итеп бастырып чыгарырга кулы җитмәде. Бәлки ул үз иҗатына карата рәхимсез таләпчән булгандыр. Югыйсә бит шигъриятне чиксез яратканлыгы һәрчак сизелә иде. Халыкның милли рухын шигырьдә гаҗәеп тел хасияте аша чагылдыра алган ике шагыйрьне – Мөдәррис Әгъләмов белән Зөлфәтне – поэзиябезнең бәхетле ачышы дип саный иде. Рәшит һәм Роберт Әхмәтҗановларны ул бик хөрмәт итә, дустанә мөнәсәбәттә иде. Шигырьләрен яттан белә, әңгәмә сөрешенә урынын чат китереп, хикмәтле юлларын әйтеп куя, әмма үз шигырьләрен беркайчан да

сөйләргә базмады, үтенгән очракта да сүзне икенчегә бора, ә күзләрендә – эчке халәтенең ризасызлыгын сиздерәсе килмәгән ниндидер нәүмиз моңсулык оеп кала иде сыман.

Шагыйрь кәгазьгә төшергәнче, күңеленнән сүз белән көрәшә, уй-хисләрен чарлый, үз-үзен кисәтә. Менә аның «Сүз – ефәк ул» дигән шигыреннән юллар:

Каючылар, каеп тукыманы,
Курчак ясап куя кешедән.
Мең кат үлчә, шагыйрь, сүзләреңне:
Дөнья карый синең эшеңә.